| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОКЫРЛАЙСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,<br>Арский муниципальный район, 422022 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ КЫРЛАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422022 |

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2022 ел** **№ 8**

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Иске Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә авылында Өтнә авылы, Салих Сәйдәшев урамы, 16а йорты, Өтнә авыл мәчете адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 23 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, 75 яшьтән узган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү , шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

**1. Җирлектәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

-юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Өтнә авылы Салих Сәйдәшев урамы-67м.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

5. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Өтнә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына: ТР, Арча районы, Өтнә авылы, Салих Сәйдәшев урамы, 16а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин